ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 11 июлендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 8 (II өлеш), № 12 (X өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 12 (I өлеш); 2012, № 1, № 9; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 1 өлешендә:
а) «д» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«д) яшәү урыны буенча торак урында теркәлгән гражданнар санын раслаучы белешмәләр;»;
б) «ж» пунктчасында «орган (алга таба – хокукларны теркәү органы) белешмәсе» сүзләрен «органнан (алга таба – хокукларны теркәү органы) белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

2) 10 статьяның «ж» пунктчасында:
а) уникенче абзацта «акчалата түләүләр» сүзләреннән соң «(компенсацияләр)» сүзен өстәргә;
б) ундүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 12 статьяның 8 өлешендә «уңышлардан, продукциядән һәм керемнәрдән файдалану турында» сүзләрен «уңышларны, продукцияне һәм керемнәрне бүлү турында» сүзләренә алмаштырырга;

4) 14 статьяда:
а) 1 өлештә «исәпләнелә» сүзен «билгеләнә» сүзенә алмаштырырга;
б) 2 өлештә «исәпләнелә» сүзен «билгеләнә» сүзенә алмаштырырга;
в) 3 өлештә «исәпләнелә» сүзен «билгеләнә» сүзенә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 06 август
№ 63-ТРЗ